МИНИСТЕРСТВО ФИНАНСОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ФИНАНС МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

25 .09.2015 № 15-94

Казан ш.

**Гражданнар мөрәҗәгатьләрен анализлау тәртибен раслау турында**

“Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында” 12 май, 2003 ел, № 16-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 23 статьясы нигезендә, боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына алынган гражданнар мөрәҗәгатьләрен анализлау тәртибен (кушымта итеп бирелә) расларга.

2. Гомуми бүлеккә (А.Г.Камалова) ярты еллык, еллык йомгаклар буенча Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына алынган гражданнар мөрәҗәгатьләрен анализлауны хәл итәргә.

3. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Министр Р.Р.Гайзатуллин

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының, № боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына алынган гражданнар мөрәҗәгатьләрен анализлау тәртибе**

1. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына (алга таба – Министрлык) алынган гражданнар мөрәҗәгатьләрен анализлауның бу Тәртибе “Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында” 12 май, 2003 ел, №16-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 23 статьясын үтәү йөзеннән эшләнде.

2. Министрлыкка алынган гражданнар мөрәҗәгатьләрен анализлау гражданнар мөрәҗәгатьләрен карап тикшерү эше сыйфатын яхшырту, җәмәгатьчелек фикерен һәм гражданнарның актуаль проблемаларын өйрәнү, шулай ук гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү формаларын һәм ысулларын камильләштерү, аларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауның сыйфатын яхшырту максатыннан чыгып хәл ителә.

3. Министрлыкта алынган гражданнар мөрәҗәгатьләрен анализлау тиешле чорда алынган гражданнарның барлык мөрәҗәгатьләре буенча, шул исәптән язмача, Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган Интернет-кабул итү бүлеге аша җибәрелгән электрон документ рәвешендә, шулай ук министр, министрның беренче урынбасары, министр урынбасарлары (алга таба – гражданнарны шәхсән кабул итү буенча вәкаләтле затлар) тарафыннан гражданнарны шәхсән кабул итү барышында алынган мөрәҗәгатьләр буенча хәл ителә.

4. Министрлыкка алынган гражданнар мөрәҗәгатьләрен анализлау нәтиҗәләре буенча гомуми бүлек хисап ярты еллыгыннан, хисап елыннан соң килүче айның 10 нчы числосына кадәр аналитик белешмә төзи.

5. Аналитик белешмә кабул итеп алынган, башка адреска җибәрелгән һәм карап тикшерелгән язмача мөрәҗәгатьләр, электрон документлар рәвешендәге мөрәҗәгатьләр саны, гражданнарны кабул итү урыннары, көннәре һәм сәгатьләре турында, шәхсән кабул итү вакытында кабул ителгән гражданнар саны турында, гражданнарны шәхсән кабул итү һәм шәхсән күчмә кабул итү буенча вәкаләтле затлар турында, мөрәҗәгатьләр тематикасы турында, мөрәҗәгатьләрне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча

кабул ителгән чаралар турында, шул исәптән кабул ителгән норматив-хокукый актлар һәм башка актлар (булганда) турында мәгълүматлардан торырга тиеш.

6. Тиешле чорда Министрлыкка алынган гражданнар мөрәҗәгатьләрен анализлау алдагы елның шушы ук чорында алынган гражданнар мөрәҗәгатьләрен чагыштыру юлы белән хәл ителә.

7. Гомуми бүлек, хисап ярты еллыгыннан, хисап елыннан соң килүче айның 15 нче числосына кадәр, Татарстан Республикасы Хөкүмәте порталында Министрлыкның рәсми сайтында (www.minfin.tatarstan.ru) “Гражданнар мөрәҗәгатьләре һәм гаржданнарны кабул итү бүлегендә аналитик белешмәне урнаштыруны тәэмин итә.